МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.10.2021 г.Казань № 739

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 29 октяберендә 8045 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2008 елның 16 апрелендәге 158 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2008 елның 16 апрелендәге 158 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык преамбуласында «(алга таба - Министрлык)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

- «Татарстан Республикасы социаль яклау отличнигы» күкрәк билгесен;

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының хезмәт сагы буенча мактау билгесен;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының мактау грамотасын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәхмәт хатын;

- Һөнәргә тугрылык өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы рәхмәтен.»;

2.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. 1-$4^1$ кушымталар нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль министрлыгының (алга таба – Министрлык) әлеге боерыкның 1 пунктында санап үтелгән ведомство бүләкләре турындагы нигезләмәләрне.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бүләкләү өчен материаллар әзерләү эшен оештыру, шулай ук бүләкләү документларын рәсмиләштерү буенча методик кулланма әзерләүне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә йөкләргә.»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ кушымта өстәргә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2008 елның 16 апрелендәге 158 номерлы боерыгына $4^1$ кушымта
(Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 8 октябрендәге 739 номерлы боерыгы редакциясендә)

Һөнәргә тугрылык өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы рәхмәте турында нигезләмә

1. Һөнәргә тугрылык өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы рәхмәте (алга таба – Рәхмәт) социаль-хезмәт өлкәсе оешмаларында, соңгы эш урыны буенча кимендә 3 еллык стажны да кертеп, кимендә 15 еллык эш стажы булган Татарстан Республмкасы социаль-хезмәт өлкәсе хезмәткәрләрен һәм тармак ветераннарын күп еллык намуслы хезмәте һәм югары проессиональлеге өчен билгеләп үтү формасы булып тора.

2. Рәхмәт белән бүләкләү яисә бүләкләүдән баш тарту турындагы карар Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә.

3. Рәхмәт белән бүләкләү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыгы нигезендә, министр урынбасарлары, Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, территориаль органнар һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре үтенечe буенча башкарыла.

4. Бүләкләү турындагы үтенеч министр исеменә тапшырыла. Рәхмәт белән бүләкләү турындагы үтенечкә 9 нчы кушымта нигезендә Рәхмәт белән бүләкләүгә тәкъдим итү хаты да теркәлергә тиеш.

5. Рәхмәтне тапшыру тантаналы шартларда министр яисә аның кушуы буенча үзенә карата Рәхмәт белән билгеләп үтү турында карар кабул ителгән затның эш урыны буенча башка вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

Министр Э.Ә. Зарипова